| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.03.2019 № 244

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы хәрби – патриотик тәрбия һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча зона үзәген төзү турында

Россия Федерациясе гражданнарын 2020 елга кадәр хәрби хезмәткә әзерләүнең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 3 февралендәге 134-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган федераль системасы Концепциясен гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында гражданнарны хәрби – патриотик тәрбияләү һәм хәрби хезмәткә әзерләү эшен камилләштерү, шулай ук Татарстан Республикасы Премьер – министрының 2017 елның 11 апрелендәге 18190-АП номерлы күрсәтмәсен гамәлгә ашыру максатында

КАРАР БИРӘМ:

1. «Армиягә, авиация һәм флотка ярдәм итү буенча ирекле җәмгыять» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең Нурлат җирле оешмасы (ДОСААФ) базасында гражданнарны хәрби-патриотик тәрбияләү һәм хәрби хезмәткә әзерләү буенча зона үзәген төзергә.

2.Гражданнарны хәрби – патриотик тәрбияләү һәм хәрби хезмәткә әзерләү буенча зона үзәге турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

3.Гражданнарны хәрби – патриотик тәрбияләү һәм хәрби хезмәткә әзерләү буенча зона үзәге советының Координация составын расларга (2 нче кушымта).

4.Хәрби – патриотик тәрбия зона үзәге эшчәнлеген методик яктан тәэмин итү һәм хәрби хезмәткә әзерлек эшләрен Нурлат муниципаль районы хәрби комиссариатына йөкләргә.

5.Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә проект документларының тулы пакетын эшләргә һәм төзергә.

6.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

Раслыйм:
Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль
районы Башкарма комитеты җитәкчесе
_____________________ Л.Н. Маняпов

Хәрби-патриотик тәрбия һәм гражданнарны
хәрби хезмәткә әзерләү буенча зона үзәге турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гражданнарны хәрби-патриотик тәрбияләү һәм хәрби хезмәткә әзерләү буенча зона үзәге (алга таба – Үзәк) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 3 февралендәге 134-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2020 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү федераль системасы концепциясен, шулай ук Татарстан Республикасы Премьер – министрының 2017 елның 11 апрелендәге 18190-АП номерлы күрсәтмәсен гамәлгә ашыру максатларында «Армия, авиация һәм флотка ярдәм итү буенча ирекле җәмгыять» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең Нурлат җирле оешмасы (ДОСААФ) базасында оештырыла.

1.2. Үзәк гражданнарны (яшьләрне) хәрби хезмәткә әзерләү бурычларын хәл итүне тәэмин итә торган (урта (тулы) гомуми белем бирү учреждениеләрен, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләрен, хәрби-патриотик юнәлештәге балалар һәм яшьләр берләшмәләрен) бердәм системага берләштерә торган, армиягә кадәрге яштәге яшьләрне Ватанны һәм хәрби хезмәткә эндәүне тәэмин итүче махсус укыту-тәрбия комплексы булып тора.

1.3. Үзәк үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## II. Үзәкнең максатлары

2.1. Россия Федерациясе законнары белән каралган гражданнарны (яшьләрне) хәрби хезмәткә һәм хәрби-патриотик тәрбия бирүгә мәҗбүри әзерләү чараларын оештыру, контрольдә тоту һәм методик яктан тәэмин итү.

2.2. Гражданнарны хәрби-патриотик тәрбияләү үсешен, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итү абруен ныгыту.

2.3. Яшьләрдә Ватанны саклауга мораль-психологик һәм физик әзерлекне, Конституция һәм хәрби бурычына тугрылык, югары гражданлык җаваплылыгы формалаштыруны тәэмин итү.

2.4. Россия Федерациясе Кораллы көчләрен хәрби һәм дәүләт хезмәтен үтүгә югары мотивацияле гражданнар белән уңышлы комплектлау өчен шартлар формалаштыруга булышлык күрсәтү.

2.5. Спорт-патриотик тәрбияне үстерү, ГТО нормативларын уңышлы үтәгән яшьләр санын арттыру өчен шартлар тудыру.

2.6. Хәрби-патриотик һәм хәрби-спорт чараларын үткәрү.

## III. Зона үзәге бурычлары

Үзәк түбәндәге бурычларны үти:

3.1. Гражданнарга оборона өлкәсендә башлангыч белемнәр бирү.

3.2. Урта гомуми белем бирү программасын яки урта һөнәри белем бирү һәм укыту пунктларында үзләштерү кысаларында мәгариф оешмаларында хәрби хезмәт нигезләре буенча гражданнарны әзерләү.

3.3. Хәрби-патриотик тәрбия бирү.

3.4. Хәрби комиссариат юлламасы буенча солдатларны, матросларны, сержантларны һәм старшиналарны хәрби-исәп белгечлекләре буенча әзерләү.

## IV. Үзәкнең эш тәртибе

4.1. Үзәк «Армия, авиация һәм флотка ярдәм итү буенча ирекле җәмгыять» (ДОСААФ) төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең Нурлат җирле оешмасы базасында оештырыла.

4.2. Үзәк Нурлат муниципаль районының мәгариф оешмалары һәм спорт учреждениеләре белән хезмәттәшлек итә, хәрби-гамәли һәм техник спорт төрләре түгәрәкләре оештыруда, гражданнарны хәрби-патриотик тәрбияләү һәм хәрби хезмәткә әзерләү буенча чаралар үткәрүдә ярдәм күрсәтә.

4.3. Совет җәмәгать башлангычларында эшли.

4.4. Үзәк эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итүне ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башкара.

4.5. Үзәк структурасы үз эченә:

- Үзәк җитәкчесе
- Үзәкнең Координация советын ала.

Үзәк Җитәкчесе:

- әлеге Нигезләмә, мәгариф һәм спорт һәм яшьләр сәясәте органнары һәм Нурлат муниципаль районы Хәрби комиссариаты боерыклары, инструкцияләре нигезендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра;
- үзәк эше белән җитәкчелек итә, эш планын һәм Совет утырышларының көн тәртибен билгели,Совет утырышын алып бара, Совет утырышларының эш беркетмәләрен һәм көн тәртибен раслый, аның эшчәнлегенең барлык юнәлешләре буенча үзәк эшен оештыра һәм контрольдә тота;
- хәрби-патриотик тәрбия һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү чараларын оештыру өчен кирәкле шартлар булдыра;
- Совет эшчәнлеге мәсьәләләре буенча мәгълүмати-аналитик документларны гомумиләштерә һәм Совет рәисенә тапшыра;

- Совет карарларының үтәлешен контрольдә тота.

Үзәк Советы:

- Үзәкнең фәнни-оештыру, фәнни-тикшеренү, фәнни-проект, гамәлгә кертү һәм башка эшчәнлегендә ярдәм күрсәтә;

- Советның перспективалы, еллык, айлык планнарын раслый;

- эшчәнлек мәсьәләләре буенча Совет әгъзалары белән методик һәм консультация эшен алып бара.

4.6. Совет утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Рәис инициативасы белән Советның чираттан тыш утырышлары үткәрелә ала.

4.7. Совет утырышларының эш планы һәм көн тәртибе Совет әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә формалаша.

4.8. Һәр календарь елына Совет рәисе тарафыннан раслана һәм муниципаль берәмлек администрациясе башлыгы белән килештерелә торган эш планы раслана.

4.9. Совет әгъзалары утырышларда шәхсән катнаша. Кирәк булганда, Совет утырышларында катнашырга башкарма хакимият органнары, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары вәкилләре, хәрби-патриотик тәрбия бирүне гамәлгә ашыручы оешмалар вәкилләре, башка затлар чакырыла ала.

4.10. Совет карарлары, әгәр утырышта Совет әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, уң як санала. Карарлар Совет утырышында катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул Совет рәисе һәм секретарь тарафыннан имзалана.

## V. Финанс һәм матди-техник тәэмин итү
## VI.

5.1. Үзәк эшчәнлеген финанслауның төп чыганагы булып бюджет акчалары хезмәт итә.

5.2. Үзәк хәрби-патриотик тәрбия һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча чараларны оештыру һәм үткәрү өчен билгеле бер укыту-матди базага ия (уку кабинетлары, спорт залы һ.б.) һәм аны камилләштерү буенча чаралар күрә.

Раслыйм:
Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль
районы Башкарма комитеты җитәкчесе
________________________ Л.Н. Маняпов

## Нурлат муниципаль районы хәрби – патриотик тәрбия һәм гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча зона үзәге Советының координацион составы

| | |
|---|---|
| Маняпов Линар Нурислам улы | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Совет әгъзалары | |
| Шагаева Эльмира Минталиб кызы | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| Абдуллин Заһир Кәрим улы | Татарстан Республикасы Нурлат районы хәрби комиссары (килешү буенча) |
| Гыйниятуллин Радик Габдулла улы | «Армия, авиация һәм флотка ярдәм итү буенча иректе җәмгыять» (ДОСААФ) төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең Нурлат җирле оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Фәтхетдинова Румия Минсалих кызы | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы |
| Газизова Чәчәк Зәйнулла кызы | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы |
| Тихонов Алексей Борис улы | «ЮНАРМИЯ " хәрәкәтенең Нурлат җирле бүлекчәсе штабы начальнигы (килешү буенча) |
| Садретдинова Разия Идрис кызы | Нурлат районы ветераннар Советы рәисе (килешү буенча) |
| Садртдинов Альберт Хәбибулла улы | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (мәктәп) формированиеләре үзәге» МБУ директоры (килешү буенча) |
| Сафиуллин Ришат Рәшит улы | «Әфганстан республикасында сугыш һәм башка локаль конфликтлар инвалидларының Татарстан Республика иҗтимагый оешмасының Нурлат |

| | |
|---|---|
| | бүлекчәсе» җирле иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Любецкий Александр Константин улы | Иделбуе казак гаскәрләре җәмгыятенең Сембер округы казак җәмгыятенә караган Нурлат станицасы казак җәмгыяте атаманы(килешү буенча) |
| Смолькина Эльмира Йосыф кызы | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы ата-аналар комитеты рәисе (килешү буенча) |

Күзәтүчеләр

| | |
|---|---|
| Әбелханов Наил Барый улы | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы мөхтәсибе (килешү буенча) |
| Имуков Василий Евгений улы | ТР Нурлат муниципаль районының благочинные Василий атакай, Нурлат шәһәренең Илья пророк чиркәве башлыгы (килешү буенча) |
| Заятдинов Сәйәр Рафаэль улы | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы прокуроры (килешү буенча) |